КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 20 март г.Казань № 6-620

1. Яңа коронавирус инфекциясе таралуга, нефтькә бәяләрнең һәм доллар курсының үзгәрүчәнлегенә бәйле рәвештә, хәлләрнең начараюы шартларында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча чаралар планын (алга таба – План) расларга.

2. Планны тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Планны тормышка ашыру барышы турындагы мәгълүматны Планда билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертергә.

3. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә Планны тормышка ашыру барышы турындагы мәгълүматны Планда билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин